**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «29» гыйнварыннан № 13

### Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составындагы үзгәрешләр турында

Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссиянең кайбер әгъзалары китү сәбәпле, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елның 12 мартындагы 66 номерлы карар белән расланган Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составына кертергә:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече Әхмәтова Ленуза Ленар кызын, аны әлеге ведомствоара комиссиянең секретаре итеп билгеләп куярга;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Камалетдинов Дамир Рөстәм улын һәм аны әлеге ведомствоара комиссиянең рәисе итеп билгеләргә.

1.2. Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составыннан Кәбирова Диләрә Накыйп кызын, Фасахов Ринат Рифгать улын төшереп калдырырга.

2. Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «12» мартыннан
66 номерлы карарына
кушымта
(Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының түбәндәге
карарлары редакциясендә:
2025 елның 15 декабрендәге 279 номерлы
2026 елның 29 гыйнварындагы 13 номерлы)

Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составы

Ведомствоара комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Камалетдинов Дамир Рөстәм улы | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |

Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Попкова Наталья Владимировна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |

Ведомствоара комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Әхмәтова Ленүзә Ленар кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге баш белгече |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Нуретдинова Алия Рөстәм кызы | - | Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Чистай, Спас, Алексеевск һәм Яңа Чишмә районнарында территориаль бүлеге эксперт-белгече |
| Пузикова Нина Ивановна | - | Россия Федерациясе пенсия һәм социаль |

| | | |
|---|---|---|
| | | иминият фонды бүлегенең Татарстан Республикасы буенча Яңа Чишмә районында клиентлар хезмәте (бүлек хокукларында) җитәкчесе |
| Филатова Светлана Сергеевна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы |
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | - | карала торган мәсьәләгә карап |